Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Кибәче авыл җирлеге Төбәк торак пунктында

# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

08.11.2019 № 1

06.10.2003 ел, № 131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» гы Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына, Саба муниципаль районы Олы Кибәче авыл җирлеге Уставының 22 нче маддәсенә, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Кибәче авыл җирлеге Советының 25.10.2009 ел, № 19 номерлы «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Кибәче авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау турында " карарына таянып, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Кибәче авыл җирлегенең Төбәк торак пункты территориясендә халык җыены карар итте:

1. 2020 нче елда Саба муниципаль районының Олы Кибәче авыл җирлеге Төбәк торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерергә:

- Төбәк авылында Бөек Ватан сугышы ветераннарына һәйкәл төзү һәм аны карап тоту.

3.Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru һәм Саба муниципаль районы Олы Кибәче авыл җирлегенең рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча: http://saby.tatarstan.ru/kibiachi бастырып чыгарырга.

Җыенда рәислек итүче:
Олы Кибәче авыл
җирлеге башлыгы А.К. Сафин